Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Әлмәт авыл Советы

КАРАРЫ

7 декабрь 2022 ел — № 53

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Әлмәт муниципаль районы территориясендә урнашкан җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешүләр төзү тәртибе хакында» Әлмәт муниципаль районының 2015 елның 6 маендагы 468 номерлы карары нигезендә

Әлмәт авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге адреслар бирү, адресларны үзгәртү, бетерү, урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирү (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге юлларыннан тыш), җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару, мәгълүматны дәүләт адреслы реестрында урнаштыру өлешендә аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советына карауга җибәрергә..

3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, бетерү, урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирү (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге юлларыннан тыш), җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару, мәгълүматны дәүләт адреслы реестрында урнаштыру өлешендә аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы Әлмәт

муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлек бюджетында билгеләргә тәкъдим итәргә

4. Әлеге карарны Молодежный бистәсе, Мәктәп урамы, 3 йорт, Дербедень авылы, Совет урамы, 32А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

.

5. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Әлмәт авыл
җирлеге башлыгы В.И.Газизова